ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.mailto:adm.jutaza@tatar.ruru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 7** **23 ноябрь 2020 ел**

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пунктында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә кабул ителгән 8 санлы карары белән Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Ютазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**К А Р А Р И Т Т Е:**

1. 2021 елда Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пунктында гражданнардан үзара салым (бер тапкыр түләү) акчаларын кертү мәсьәләсе буенча киңәшмәне Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пунктында гражданнар җыены 2 этапта уздырырга:

- 2020 елның 3 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Ютазы авылы, Дмитров урамы, 9 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасы янында гражданнар җыененың беренче этабы.
- 2020 елның 4 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Ютазы авылы, Дмитров урамы, 9 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасы янында гражданнар җыененың икенче этабы.

3. Җыенда катнашучылар исемлегенә Ютазы торак пунктында теркәлгән кешеләрне кертергә.

4.Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Ютазы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, балачактан инвалид булган, I һәм II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

1) Ютазы торак пунктында Вахитов, Комсомольская, Ворошилов урамнарындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, асфальтлау, юллар һәм тротуарлар төзү, төзелеш материаллары сатып алу, таш ташу, таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Ютазы торак пунктында төзекләндерү ( коры агачлар, куакларны кисү, территорияне җыештыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Ютазы авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

6. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов